| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

| | |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 2015 ел, 30 апрель | № 305 |

г. Казань

«Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсы турында

Халыкны әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләрен хәл итүгә җәлеп итү, яшьләргә экология тармагындагы проблемаларга карата үз мөнәсәбәтләрен белдерергә, социаль рекламаны үстерүгә үз өлешләрен кертергә мөмкинлек бирү, шулай ук сәләтле (талантлы) яшьләргә ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү турында Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Теркәлә торган Конкурс турында Нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына Конкурсны оештыру һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Конкурс чараларын финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау, табигый байлыкларны яңадан җитештерү һәм файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау, табигый байлыкларны яңадан җитештерү һәм файдалану» дәүләт программасын тормышка ашыруга каралган акча хисабына тормышка ашырыла дип билгеләргә.

5. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында Конкурсны мәгълүмати яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына «Рәсми Татарстан» порталында һәм «Татарстан Республикасында Электрон мәгариф» мәгълүмат системасында мәгълүмати баннер урнаштырырга.

7. Әлеге карар үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\305.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 30 апрель, 305 нче
карары белән расланган

**«Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсы турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсының (алга таба – Конкурс) үткәрү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.
1.2. Конкурс 2015 елның 1 июненнән 1 сентябренә кадәр үткәрелә.
1.3. Конкурсның оештыручысы булып Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тора.

2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның төп максатлары түбәндәгеләр:
халыкны әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләрен хәл итүгә тарту;
яшьләргә экология тармагындагы проблемаларга карата үз мөнәсәбәтләрен белдерү мөмкинлеге бирү;
яшь талантларны Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясендә социаль экологик рекламаны тудыруда катнаштыру.
2.2. Конкурсның төп бурычлары түбәндәгеләр:
яшь кешеләрдә әйләнә-тирә мохиткә сакчыл мөнәсәбәт принципларын булдыруга булышлык итү;
яшьләрне социаль иҗат, әхлак һәм гражданнар тәрбияләү тармагына җәлеп итү;
яшьләр тарафыннан экологик проблемаларны хәл итүгә шәхси кертем ясау кирәклеген аңлау;
Конкурста катнашучыларның социаль эшләрен мәгариф оешмаларында, массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру юлы белән яшьләрнең экологик культурасын арттыру.

3. Конкурс номинацияләре һәм конкурс эшләренә таләпләр

3.1. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:
«Социаль плакат» ике яшь категориясендә:
кече (5 яшьтән алып 14 яшькәчә);
өлкән (5 яшьтән алып 35 яшькәчә);
«Фотография» ике яшь категориясендә:
кече (5 яшьтән алып 14 яшькәчә);

өлкән (5 яшьтән алып 35 яшькәчә);
«Социаль видеоролик»;
«Кыска метражлы фильм»;
Югарыда китерелгән барлык номинацияләрдә һәм яшь төркемнәрендә «Халык тавыш бирүе җиңүчесе».

3.2. Конкурс эшләрендә атмосфера һавасын, су һәм җир ресурслары саклау тармагында, производство һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә, шулай ук үсеп килүче буынга экологик тәрбия һәм белем бирү мәсьәләләрендә Россия Федерациясе өчен аеруча актуаль булган экологик проблемаларны хәл итү юлларын, вариантларын, идеяләрен, якын килүне чагылдырырга кирәк.

3.3. Конкурс эшләренә карата техник таләпләр:
«Социаль плакат» номинациясендә:
плакат макеты (плакатлар сериясе, әмма 10 файлдан да күп түгел) JPEG форматында 300 dpi ким булмаган ачыклану дәрәҗәсе белән, А4 форматында бастыру өчен яраклы булырга тиеш, файл 10 МБ артмаска тиеш;
плакатта слоган урнаштырыла ала;
эшкә эшнең кыскача тасвирламасы бирелә (20 сүздән артык түгел).

Кеше яшь категориясендә кулдан яки компьютер графикасы ярдәмендә башкарылган эшләр кабул ителә. Кулдан эшләнгән плакатлар фотографиягә төшерелә яки сканерланалар.

Өлкән яшь төркемендә график программалар кораллары ярдәмендә башкарылган эшләр кабул ителә;
«Фотография» номинациясендә:
фотография (фотографияләр сериясе, әмма 10 файлдан да күп түгел) JPEG форматында 300 dpi ким булмаган ачыклану дәрәҗәсе белән, А4 форматында бастыру өчен яраклы булырга тиеш, файл 10 МБ артмаска тиеш;
фотографиядә язулар һәм слоганнар урнаштырылырга тиеш түгел;
эшкә эшнең кыскача тасвирламасы бирелә (20 сүздән артык түгел);
«Социаль видеоролик» һәм «Кыска метражлы фильм» номинацияләрендә:
видео MP4 форматында тапшырыла, файл 150 МБ артмаска тиеш;
видео башланганда түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:
Конкурс, эш исеме (Конкурс логотипын кулланып), авторның (авторлар коллективының) фамилиясе, исеме, төбәк, торак пункты атамасы;
социаль видеороликның хронометражы – 30 секундтан артык түгел;
кыска метражлы фильмның хронометражы – 5 минуттан артык түгел;
һәр эш сценариесенең текст тасвирламасы белән тапшырыла.

## 4. Конкурста катнашу шартлары

4.1. 5 яшьтән алып 35 яшькәчә (35 яшьне кертеп) Россия Федерациясе гражданнары (аерым авторлар һәм коллективлар) Конкурсның катнашучысы була ала.

Конкурста катнашырга дәгъва белдерүче һәркем һәр номинация буенча 5 тән артык булмаган гариза бирә ала.

4.2. Конкурста катнашу өчен түбәндәгеләр кирәк:

Конкурсның https://чистыйвзгляд.рф рәсми сайтында (алга таба – Конкурсның рәсми сайты) теркәлергә;

Конкурсның рәсми сайтында гариза һәм конкурс эшен тапшырырга.

4.3. Гариза һәм конкурс эше кергән көннән соң календарь көннәрендә саналган ун көн эчендә катнашучыга конкурс эшенә Конкурста катнашырга рөхсәт итү турында яисә, баш тартуның сәбәбен күрсәтеп, Конкурста катнашырга рөхсәт итмәү турында хәбәр килә.

4.4. Түбәндәге очракларда Конкурста катнашырга рөхсәт булмый:

конкурс эшенең әлеге Нигезләмәнең 3.2 һәм 3.3 пунктлары таләпләренә туры килмәве;

конкурс эшендә дөрес булмаган белешмәләр булу;

конкурс эшендә плагиат булу;

конкурс эше эчтәлеге, сюжеты, сәхнәдәге затлар һәм персонажларның Россия Федерациясе законнарына каршы килүе;

конкурс эше элек моңа охшаш конкурсларда призлы урыннар алган булса.

4.5. Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән эшләр конкурс эшен кабул итү турында хәбәр җибәрелгән көннән соң өч көн эчендә гомуми тавыш бирү өчен сайтта урнаштырыла.

4.6. Номинацияләрнең һәркайсында иң күп тавыш җыйган эшләр халык тавыш бирүе җиңүчеләре дип таныла һәм эксперт комиссиясе тарафыннан җиңүчеләрне сайлауда катнашмый.

Әгәр бер автор ике яки күбрәк номинациядә иң күп тавыш җыйган очракта, ул күбрәк тавыш җыйган номинациядә җиңүче дип таныла, икенче номинациядә аннан соң килә торган катнашучы җиңү яулый.

4.7. Конкурсның бер номинациясендә җиңгән автор Конкурсның башка номинацияләрендә җиңүче исеменә дәгъва итә алмый.

4.8. Конкурста катнашкан өчен түләү алынмый.

## 5. Конкурсны оештыручы

5.1. Конкурсны оештыручы:

эксперт комиссиясен оештыра;

Конкурсны үткәрү шартлары турында катнашучыларга үз вакытында мәгълүмат бирә;

Конкурс эшләренә Конкурста катнашырга рөхсәт итү турында яисә Конкурста катнашырга рөхсәт итмәү турында карарлар кабул итә;

Конкурс үткәрү барышы һәм аның нәтиҗәләре турында массакүләм мәгълүмат чараларына мәгълүмат бирә;

Конкурс йомгаклары турында эксперт комиссиясе карарын раслый;

Конкурс җиңүчеләрен бүләкләү тантанасын оештыра.

## 6. Эксперт комиссиясе

6.1. Конкурс җиңүчеләрен билгеләү һәм йомгакларын ясау өчен эксперт комиссиясе төзелә, аның составы 2015 елның 1 сентябренә кадәр оештыручы боерыгы белән раслана.

6.2. Эксперт комиссиясе Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, иҗтимагый оешмалар, фәнни берлекләр, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләреннән формалаша.

6.3. Эксперт комиссиясе 2015 елның 15 сентябренә кадәр уртак утырышта конкурс эшләрен карап тикшерә һәм ачык тавыш бирү юлы белән һәр номинация буенча Конкурс җиңүчеләрен билгели.

6.4. Эксперт комиссиясе әгъзаларының тавышлары тигез санда булган очракта эксперт комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч була.

6.5. Эксперт комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм эксперт комиссиясе рәисе тарафыннан имзалана.

## 7. Конкурс эшләрен бәяләү критерияләре

7.1. Конкурс эшләре эксперт комиссиясе тарафыннан түбәндәге критерияләр буенча бәяләнәләр:

конкурс эшенең дәлилле булуы һәм эчтәлегенең ачылу тирәнлеге;

белемлелек, чишелешнең профессиональлеге, реклама, социаль методикалар һәм технологияләрнең нәтиҗәлелеге;

конкурс эшенең социаль әһәмияте, позитивлыгы һәм креативлыгы (идея яңалыгы, үзенчәлекле булуы);

бәян итү теле һәм стиленең төгәл һәм анык булуы;

төс, яктылык, шрифт, рәсем, график элементлар, интонация һ.б. җиткерә торган эмоциональ буяулар булу.

## 8. Җиңүчеләрне бүләкләү

8.1. Конкурста катнашучыларның барысы да электрон рәвештә Конкурста катнашучы сертификаты ала.

8.2. Конкурс җиңүчеләренә Казан шәһәрендә бүләкләү тантанасында дипломнар, кубоклар һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырыла.

Бүләкләү тантанасында җиңүчеләрнең шәхсән катнашулары приз һәм кубокны алуның мәҗбүри шарты булып тора.

8.3. Конкурс җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы 2015 елның 1 октябренә кадәр оештырыла һәм үткәрелә.

8.4. Конкурс йомгаклары җиңүчеләрне бүләкләү тантанасыннан соң өч көн эчендә Конкурсның рәсми сайтында урнаштырыла.

8.5. Конкурсның оештыручысы түбәндәгеләргә хокуклы:

конкурс эшләрен коммерциячел булмаган максатларда һәм авторга (авторлар коллективына) акчалата бүләкләү түләмичә, әмма автор (автордашлар) исемен һичшиксез күрсәтеп, файдаланырга;

конкурс эшләре базасында (электрон каталог, интернет-ресурслар) тудырылган социаль реклама кампанияләре үткәрергә;

конкурс эшләрен гомуми белем бирү оешмаларында һәм профессиональ белем бирү оешмаларында таратырга;

җәмгыять өчен әһәмиятле чаралар үткәргәндә Конкурс ихтыяжлары өчен һәм аны рекламалау максатларында конкурс эшләренә репродукция ясарга;

конкурс эшләрен методик һәм мәгълүмати басмаларда, телерадиокомпанияләр эфирында трансляцияләү өчен, прессада, тышкы реклама йөртүчеләрдә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру өчен файдаланырга;

уку-укыту һәм бүтән максатларда конкурс эшләрен тулысынча яки өлешчә кулланырга.

---